**Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы**
**Иске Рәҗәп авыл җирлеге**
**Советы**

**КАРАР**

№ 1 «20 » февраль 2024 ел

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Иске Рәҗәп авыл җирлеге Советының “Җир салымы турында" 2020 елның 12 октябрендәге 7-3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2021 елның 22 июлендәге 30-1 номерлы, 2021 елның 04 октябрендәге 36-1 номерлы, 2022 елның 25 октябрендәге 70-1 номерлы үзгәрешләре белән)

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлегенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Иске Рязап авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Иске Рәҗәп авыл җирлеге Советының “Җир салымы турында" 2020 елның 12 октябрендәге 7-3 номерлы карарына (2021 елның 22 июлендәге 30-1 номерлы 2021 елның 04 октябрендәге 36-1 номерлы, 2022 елның 25 октябрендәге 70-1 номерлы үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 статьяның 1.2 пунктчасы түбәндәге эчтәлектәге икенче абзац белән тулыландырырга:

"авыл җирлеге Башкарма комитетының даими (сроксыз) файдаланудагы җир кишәрлекләренә карата”;

- 3 статьяны түбәндәге эчтәлектәге дүртенче абзац белән тулыландырырга:

"җирле үзидарә органнары, гомуми файдаланудагы территорияләр (парклар, скверлар, ял итү зоналары, урман утырту һ.б.) биләгән җир участокларына карата».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар Иске Рәҗәп торак пунктында мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш, шулай ук Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының интернет челтәрендәге рәсми сайтында - http://spasskiy.tatarstan.ru/ һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында https://pravo.tatarstan.ru/. урнаштырырга.

4. Әлеге карар үз көченә кергән көннән алып Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Иске Рәҗәп авыл җирлеге советының «Җир салымы турында» 2024 елның 29 гыйнварындагы 104 номерлы, «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Иске Рәҗәп авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2023 елның 25 октябрендәге 97-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында" карарын үз көчен югалткан дип танырга (2023 елның 08 декабрендәге 100-1 номерлы үзгәрешләре белән).

Иске Рәҗәп авыл җирлеге башлыгы М.А.Нугаев